КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2021 ел, 17 ноябрь | г.Казань | № 1090

«Казан – Екатеринбург» юнәлешен үстерү кысаларында М-7 «Волга» автомобиль юлының Мәскәү – Владимир – Түбән Новгород – Казан – Уфа участокларын төзү һәм реконструкцияләү. М-7 «Волга» автомобиль юлының 1161+000 км – 1166+710 км участогындагы Мәскәү – Владимир – Түбән Новгород – Казан – Уфа юлын реконструкцияләү, Татарстан Республикасы» проектын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен резервлау турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 70[1] статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт ихтыяҗлары яки муниципаль ихтыяҗлар өчен җирләрне резервлауга бәйле кайбер мәсьәләләр турында» 2008 елның 22 июлендәге 561 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 19 мартындагы б-384 номерлы боерыгы белән расланган федераль транспорт (тимер юл, һава, диңгез, эчке су транспорты) һәм федераль әһәмияттәге автомобиль юллары өлкәсендә Россия Федерациясен территориаль планлаштыру схемасы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «2030 елга кадәр перспектива белән 2016 – 2021 елларга Татарстан Республикасының транспорт комплексын үстерү стратегиясен раслау турында» 2017 елның 24 июлендәге 253 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Казан – Екатеринбург» юнәлешен үстерү кысаларында М-7 «Волга» автомобиль юлының Мәскәү – Владимир – Түбән Новгород – Казан – Уфа участокларын төзү һәм реконструкцияләү. М-7 «Волга» автомобиль юлының 1161+000 км – 1166+710 км участогындагы Мәскәү – Владимир – Түбән Новгород –

Казан – Уфа юлын реконструкцияләү, Татарстан Республикасы» проектын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен 1 нче кушымтада күрсәтелгән җир кишәрлекләрен (алга таба – резервлана торган җир кишәрлекләре) 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасының Актаныш муниципаль районы территориясендә урнашкан, резервлана торган җир кишәрлекләре схемасында билгеләнгән чикләрдә өч елга резервларга.

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

җир кишәрлекләренең милекчеләре, җирдән файдаланучылары, җир хуҗалары, аларны арендалаучылар хокуклары җир законнары нигезендә, җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен резервлауга бәйле рәвештә, җир кишәрлегенең максатчан билгеләнешенә һәм аны рөхсәт ителгән файдалануга карап, торак, җитештерү, мәдәният-көнкүреш һәм башка биналар, корылмалар төзү, рөхсәт ителгән файдалану нигезендә сугару, киптерү, агроурман-мелиорация, культуртехник һәм башка мелиорация эшләре үткәрү, буалар (шул исәптән су агымы урыннарында терәү итеп куелган су корылмалары белән барлыкка килгән буалар) һәм башка су объектлары төзү өлешендә чикләнә;

кызыксынучы затларны резервлана торган җир кишәрлекләре схемасы белән һәм резервлана торган җирләрнең чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең кадастр саннары исемлеге белән таныштыру Казан шәһәре, Вишневский урамы, 26 нчы йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы бинасында гамәлгә ашырыла (эш режимы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе: 9.00 – 18.00, җомга: 9.00 – 16.45, төшке аш: 11.45 – 12.30).

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына билгеләнгән тәртиптә:

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына тиешле үзгәрешләрне кертү өчен документларны Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә кертергә;

бу карарны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга;

бу карарны муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә рәсми бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасының Актаныш муниципаль районына җибәрергә.

4. Бу карар резервлана торган җир кишәрлекләре урнашу урыны буенча рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылырга тиеш һәм басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 17 ноябрь, 1090 нчы
карарына 1 нче кушымта


«Казан – Екатеринбург» юнәлешен үстерү кысаларында М-7 «Волга» автомобиль юлының Мәскәү – Владимир – Түбән Новгород – Казан – Уфа участокларын төзү һәм реконструкцияләү. М-7 «Волга» автомобиль юлының 1161+000 км – 1166+710 км участогындагы Мәскәү – Владимир – Түбән Новгород – Казан – Уфа юлын реконструкцияләү, Татарстан Республикасы» проектын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен резервлана торган җир кишәрлекләре
исемлеге

| Җир кишәрлегенең кадастр саны | Бердәм җирдән файдалануның кадастр саны |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 16:04:030503:1 | 16:04:000000:509 |
| 16:04:030503:13 | 16:04:000000:401 |
| 16:04:030503:2 | 16:04:000000:509 |
| 16:04:030503:24 | |
| 16:04:030503:25 | 16:04:000000:517 |
| 16:04:030503:30 | |
| 16:04:030503:32 | |
| 16:04:030503:33 | |
| 16:04:030503:34 | |
| 16:04:030503:39 | |
| 16:04:030503:42 | |
| 16:04:030503:43 | |
| 16:04:030503:44 | |
| 16:04:030503:45 | |
| 16:04:030503:46 | |
| 16:04:030503:5 | 16:04:000000:509 |
| 16:04:120501:10 | 16:04:000000:509 |
| 16:04:120501:116 | 16:04:000000:508 |
| 16:04:120501:117 | 16:04:000000:509 |
| 16:04:120501:143 | |
| 16:04:120501:173 | |
| 16:04:120501:26 | 16:04:000000:509 |
| 16:04:120501:40 | 16:04:000000:517 |
| 16:04:120501:75 | 16:04:000000:401 |
| 1 | 2 |

| | |
|---|---|
| 16:04:120503:71 | |
| 16:04:120503:72 | |
| 16:04:120503:73 | 16:04:000000:509 |
| 16:04:000000:872 | |
| 16:04:000000:896 | |
| 16:04:000000:897 | |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 17 ноябрь, 1090 нчы
карарына 2 нче кушымта

«Казан – Екатеринбург» юнәлешен үстерү кысаларында М-7 «Волга» автомобиль юлының Мәскәү – Владимир – Түбән Новгород – Казан – Уфа участокларын төзү һәм реконструкцияләү. М-7 «Волга» автомобиль юлының 1161+000 км – 1166+710 км участогындагы Мәскәү – Владимир – Түбән Новгород – Казан – Уфа юлын реконструкцияләү, Татарстан Республикасы» проектын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен резервлана торган җир кишәрлекләре схемасы




Масштабы 1:30 000

Файдаланылган шартлы билгеләр һәм тамгалар:

– җирләрне резервлау чиге;

– Россия Федерациясе субъекты чиге;

– авыл җирлеге чиге.